ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Тњбђн Мђтђскђ авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

*Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru*

Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты

«07» февраль 2017 ел. №2

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Кырлай авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясындагы 2 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары нигезендә, гражданнар төркеменең 2017 елның 20 гыйнварындагы Иске Кырлай авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән җир участокларының минималь зурлыгын киметү турындагы мөрәҗәгатенә бәйле рәвештә, Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр проектын әзерләүгә керешергә.

2. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын эшләү срогын 2017 елның 20 февралендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), Арча муниципаль районының рәсми сайтында, гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Арча муниципаль районы, Түбән Мәтәскә авылы, Тукай ур., 2; ТР, Арча муниципаль районы, Иске Кырлай ав., Үзәк ур., 12А й.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

*Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы* *Ф.Г.Сиражетдинов*